Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№2 21 ноябрь 2025 ел

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, тормыш иптәше), Россия Армиясенә хшрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юлларга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Урыссу торак пунктында Елга урамы буенча юлларны норматив хәлгә китерү (реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Иске Урыссу торак пунктындагы Хәтер скверы территориясенә хезмәт күрсәтү (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Урыссу торак пунктында җирлек юллары эчендә тоту (юлларны кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова